## ОНЫТМАГАН БУЛСАҢ...

*Зөфәр Хәйретдинов көе*
*Шәмсия Җиһангирова шигыре*
*(Марс Кәшипов эшкәртүендә)*

Син оныткан булсаң әгәр мине,
Назлы җилләр хәбәр китерер,
Чәчләреңнән сыйпап иркәләр дә,
Күлларымны исеңә төшерер.

> *Кушымта:*
> Онытмаган булсаң әгәр мине,
> Килер булсаң бары кичегеп,
> Көтәрмен мин, бәгърем, көтәрмен мин,
> Ялгышларның барсын кичереп.

Син оныткан булсаң әгәр мине,
Яз гөлләре хәбәр китерер.
Зәңгәр ялкын булып бөркелер дә,
Күзләремне исеңә төшерер...

> *Кушымта.*

Син оныткан булсаң әгәр мине,
Ак бураннар хәбәр китерер.
Чаллар булып чәчеңә сарылыр да,
Сагышымны исеңә төшерер...

> *Кушымта.*